**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының**

**Сәвәләй авыл җирлеге Советы**

**КАРАРЫ**

**№ 85** **29.12.2022 ел**

**«Җирле салымнар буенча пенялар һәм штрафлар буенча недоимкаларны һәм бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре турында» 2020 елның 24 декабрендагы 17 номерлы Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясы 3 пункты нигезендә, Зәй муниципаль районының Сәвәләй авыл җирлеге Советы Уставы нигезенә таянып, Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. “Җирле салымнар буенча пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләтү өметсез дип тануның өстәмә нигезләре турында» 2020 елның 24 декабрендагы 17 номерлы Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Вафат булган физик затлар яисә Россия Федерациясе граждан-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә үлгән дип игълан ителгән физик затларның бурыч барлыкка килүгә өч елдан артык дата белән җир салымы һәм мөлкәт салымы буенча;

1.2. Варислар мираска хокуктан баш тарткан, варислар булмаган яки мирасны кабул итмәгән очракта, вафат булган физик затлар яисә Россия Федерациясе граждан-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә үлгән дип игълан ителгән физик затларның мирас ачылган көннән бер ел эчендә җир салымы һәм мөлкәткә салым буенча;

1.3. Җирле салымнар буенча 2017 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдән чыгарылган салымнар буенча оешмалар, индивидуаль эшкуарлар яисә физик затлар өстендә исәпләнгән недоимка, пенялар һәм штрафлар буенча бурыч булу (реструктуризацияләү һәм банкротлык процедураларында булган салым түләүчеләрнең бурычларыннан тыш);

1.4. «Башкарма производство турында» 2007 елның 02 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясы 1 өлеше 3, 4 пунктлары белән каралган нигезләр буенча суд приставы-башкаручы тарафыннан производствоны тәмамлау турында карар чыгаруга бәйле рәвештә, салым органы тарафыннан эзләп алу мөмкин булмаган очракта, барлыкка килгән датадан өч елдан да артыграк вакытта пенялар һәм штрафлар буенча недоимкалар һәм бурычлар булу;

1.5. Суд тәртибендә хокукка сәләтсез дип танылган психик тайпылышлары булган физик затларның җир салымы һәм мөлкәтенә салым буенча;

1.6. Картлар (ветераннар) йортларында яшәүче физик затларның җир салымы һәм мөлкәтенә салым буенча;

1.7. Иректән мәхрүм итү урыннарында булган чорга иректән мәхрүм итү

урыннарындагы физик затларның җир салымы һәм мөлкәтенә салым буенча;

1.8. Әти-әнисе ата-ана хокукыннан мәхрүм ителгән балалар йортларында һәм приютларда тәрбияләнүче балигъ булмаган физик затларның җир салымы һәм мөлкәтенә салым буенча;

1.9. Әлеге карарга кушымта нигезендә җирле салымнар буенча недоимканы, әлеге салымнар буенча пенялар һәм штрафлар буенча бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләре булуын раслый торган документлар исемлеген расларга».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU), җирлекнең торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә үз җаваплылыгымда калдырам.

**Совет Рәисе ,**

**Авыл җирлеге башлыгы** **И.А. Галимов**

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Зәй шәһәре Советының
2022 елның 29 нчы декабре
85 номерлы карарына
кушымта.

**Җирле салымнар буенча недоимка, пеня һәм штрафлар буенча бурычларны түләтү өметсез дип тану өчен өстәмә нигезләр булуны раслый торган документлар исемлеге**

1. Әлеге карарның 1 пунктындагы 1.1 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:
1) недоимка суммасы һәм пенялар, штрафлар буенча бурыч турында физик затның яшәү урыны буенча салым органы белешмәсе;
2) физик затларның гражданлык хәле актларын теркәүне гамәлгә ашыручы орган тарафыннан физик затның үлү фактын теркәү турында Россия Федерациясе Салым кодексының 85 статьясы 3 пункты нигезендә салым органына кергән белешмәләр.

2. Әлеге карарның 1 пунктындагы 1.2 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:
1) недоимка суммасы һәм пенялар, штрафлар буенча бурыч турында физик затның яшәү урыны буенча салым органы белешмәсе;
2) мираска хокук турында таныклык бирү турында белешмәләр булмау турында салым органы белешмәсе.

3. Әлеге карарның 1 пунктындагы 1.3 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:
1) недоимка суммасы һәм пенялар, штрафлар буенча бурыч турында оешма, шәхси эшкуар, индивидуаль эшкуар статусын югалткан физик затны исәпкә алу буенча салым органы белешмәсе;
2) салым гамәлдән чыгарылган норматив хокукый акт (исеме, номеры, датасы) турында мәгълүматлар;
3) оешманың, шәхси эшмәкәрнең, физик затның бөлгенлек (банкротлык) турында эш кузгатыла торган процедураларда булмавы турында салым органы белешмәсе.

4. Әлеге карарның 1 пунктындагы 1.4 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:
1) недоимка суммасы һәм пенялар, штрафлар буенча бурыч турында оешма, шәхси эшкуар, индивидуаль эшкуар статусын югалткан физик затны исәпкә алу буенча салым органы белешмәсе;
2) «Башкарма производство турында» 2007 елның 02 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясы 1 өлешенең 3 һәм 4 пунктларында каралган нигезләр буенча башкарма документны кире кайтарганда башкару производствосын тәмамлау хакында суд приставы-башкаручы карары.

5. Әлеге карарның 1 пунктындагы 1.5 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:
1) недоимка суммасы һәм пенялар, штрафлар буенча бурыч турында физик затның яшәү урыны буенча салым органы белешмәсе;
2) суд карары нигезендә яисә Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге белешмәсе нигезендә.

6. Әлеге карарның 1 пунктындагы 1.6 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:
1) недоимка суммасы һәм пенялар, штрафлар буенча бурыч турында физик затның яшәү урыны буенча салым органы белешмәсе;

2) Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Зәй районындагы социаль яклау бүлеге белешмәсе нигезендә.

7. Әлеге карарның 1 пунктындагы 1.7 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:
1) недоимка суммасы һәм пенялар, штрафлар буенча бурыч турында физик затның яшәү урыны буенча салым органы белешмәсе;
2) суд карары нигезендә.

8. Әлеге карарның 1 пунктындагы 1.8 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:
1) недоимка суммасы һәм пенялар, штрафлар буенча бурыч турында физик затның яшәү урыны буенча салым органы белешмәсе;
2) - әгәр балигъ булмаган бала балалар йортында тәрбияләнсә - Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге белешмәсе нигезендә.
- әгәр балигъ булмаган бала приютта тәрбияләнсә - Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Зәй районындагы социаль яклау бүлеге белешмәсе нигезендә.